СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 12 09.04. 2015 ел

Аксубай муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы карар чыгарды :

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен җирлек башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

торак пункт чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашырудан тыш, шулай ук автомобиль юлларын куллану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитетына кабул ителгән очракта:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге

бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге

Советы Рәисе М. М. Сөләйманкин